КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 17 декабрь г.Казань № 1154

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары норматив чыгымнарын раслау турында» 2024 ел, 20 сентябрь, 816 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары норматив чыгымнарын раслау турында» 2024 ел, 20 сентябрь, 816 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 30 октябрь, 941 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар составында башка чыгымнарга төзәтү коэффициентларының 5.5 пунктчасының 3 графасында «1,16» саннарын «1,60» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль берәмлекләр (шәһәр округлары) территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар рәвешләре белән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында ятак-көннәр һәм ятак-урыннар санында:

«Азнакай муниципаль районы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Азнакай муниципаль районы | «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Азнакай муниципаль районындагы «Өмет» ХСХККҮ» социаль-тернәкләндерү бүлеге ДАСХУ | 828 | - | - | 36 | - | - »; |

«Казан шәһәре» юлының «Восхождение» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» ДАСХУ» ярдәмче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Восхождение» инвалидларны тернәкләндерү үзәге» ДАСХУ | 12 920 | 9 120 | - | 40 | 40 | - ». |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 февраленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин